чыгышлар ясый. Фәнни-эзләнү эшләренең кәгазь варианты һәм “Чын мирас” журналына 2014 елның икенче яртыеллыгына язылу турында квитанция күчерелмәсе чыгыш ясар алдыннан экспертлар комиссиясенә тапшырыла.

6.3. Конференциядә катнашу өчен 2014 елның 19 мартына кадәр фәнни эшне (7-8 бит), **“Чын мирас” журналына 2014 елның икенче яртыеллыгына язылу турында квитанция күчерелмәсен** miraskonf@mail.ru адресына секция җитәкчеләре исеменә (мисал өчен: “Ленар Гобәйдуллинга”, “Ләбиб Леронга”...) җибәрергә кирәк.

6.4. Килгән эшләрне оештыру комитеты составына кергән экспертлар тикшергәннән соң, икенче этапта катнашу өчен **2014 елның 24 мартында** чакыру хатлары җибәрелә, телефоннан шалтыратып хәбәр ителә.

6.5.Ике кешедән торган авторларның да эшләре кабул ителә ала.

7. **Бәяләү критерийлары**

Казан федераль университеты Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге; “ТАТМЕДИА” ААҖ “Чын мирас” журналы редакциясе хезмәткәрләре укытучыларның фәнни эшләрен, чыгышларын түбәндәге критерийлардан чыгып бәяләячәк:

- сайланган теманың актуаль булуы;
- проблеманы чишүнең тирәнлеге, тулылыгы, үзенчәлекле ысуллары кулланылган булуы;
- фәнни эштә логик эзлеклелек саклану;
- кулланылган әдәбиятның сыйфаты;
- авторның мөстәкыйльлек дәрәҗәсе;
- чыгышның композицион бөтенлеге, дәлилли белү, теманы ача белү дәрәҗәсе;
- чыгышны күрсәтмә материал белән баету;
- чыгыш ясаучының сөйләм, аралашу культурасы;
- жюри биргән сорауларга җавапларның сыйфаты.

Экспертлар һәр юнәлеш буенча бәя бирү критерийларын конкретлаштыру хокукына ия.

Чыгыш ясаучыга 5 минут вакыт бирелә. Шул вакыт эчендә ул төп фикерләрне кыска һәм төгәл итеп җиткерә белергә тиеш.

8. **Катнашучыларны бүләкләү**

- 1, 2 нче этапта катнашкан барлык укытучыларга да Казан федераль университеты Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге; “ТАТМЕДИА” ААҖ “Чын мирас” журналы сертификаты тапшырыла.
- Җиңүчеләр һәм призлы урын яулаучылар Казан федераль университеты Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге; “ТАТМЕДИА” ААҖ “Чын мирас” журналы редакциясе дипломнары белән бүләкләнә.
- Иң яхшы дип саналган эшләр **“Чын мирас”** журналы сәхифәләрендә басылачак.

“Туган ягым – яшел бишек” төбәкаара укытучылар конференциясенә фәнни эшне тәкъдим итү таләпләре

Мәкаләләрнең тексты электрон вариантта кабул ителә, иске фотоларның JPEK форматында яхшы сыйфатлы **электрон күчерелмәләрен** җибәрү шарт. Мәкалә күләме 7-8 бит. Шрифт Times New Roman, 14 кегель, 1,5 интервал, бит үлчәмнәре: югары һәм түбән чикләре – 2 см; сул як – 3 см; уң як – 1,5 см. Текст башында (уң якта) авторның исем-фамилияләре, **телефон номерлары**, уку яки эшләү урыны, уртада доклад исеме языла.

Аерым биткә түбәндәге таблицаны тутырып җибәрүегез шарт: